ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.01.2022 №9

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Введенская Слобода

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегендә 2022 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2022 елның 1 февраленнән 1 Кушымта һәм 2 кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

ТР Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022нче елның 28нче гыйнварыннан 9нчы номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3601,24 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 1116,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,79 |
| Барлыгы | 6 964,68 |

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022нче елның 28нче гыйнварыннан 9нчы номерлы карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 666,35 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 2934,90 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 1116,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 224678 |
| Барлыгы | 6 964,68 |